ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы
Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 116 статьяның 2 өлешендә «1 өлешендәге 7 һәм 12 пунктларында билгеләнгән» сүзләрен «1 өлешендәге 6 (баланы уллыкка алырга теләк белдерүче зат гаиләдә урнашкан мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә аның белән яшәгән очракта), 7 һәм 12 пунктларында билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $153^1$ статья өстәргә:
«$153^1$ статья. **Әлеге Кодексның аерым нигезләмәләрен куллану**

Алиментларга хезмәткә сәләтсез ярдәмгә мохтаҗ балигъ булган затларның хокукы, шулай ук пенсия яшенә җиткән ярдәмгә мохтаҗ элекке иренең (хатынының) хокукы (әлеге Кодексның 75, 77, 79, 80, 83 – 87 статьялары) шул исәптән 55 яшькә (хатын-кызлар өчен), 60 яшькә (ир-атлар өчен) җиткән затларга тарала.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 06 август
№ 61-ТРЗ